| ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ |
|---|---|---|

ПРИКАЗ БОЕРЫК

____17.09.2018______ г. Казань № ___84_____

Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 02.11.2010, № 880, «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 12.11.2007, № 622 карарларына туры китереп

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымта итеп бирелүче административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Начальник урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга: Регламент нигезләмәләренә тайпылышсыз таянып эш итәргә.

3. Хокук идарәсенең юридик бүлегенә: дәүләт теркәвенә алу өчен, бу боерыкны билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Җыелма анализ бүлгенә: Регламентны Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе рәсми сайтына урнаштырырга.

5. Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең түбәндәге боерыкларын көчләрен югалткан дип танырга:

«Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 23.01.2012, № 3;

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 23 гыйнварындагы 3 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында» 29.05.2014, № 53;

Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентлар һәм проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2012 елның 23 гыйнварындагы 3 номерлы боерыгы белән расланган административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 04.10.2016, № 67.

6. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башлыгының беренче урынбасары И.Ф. Сафиуллинга йөкләргә.

Башлык В.А. Кудряшов

Татарстан Республикасы Дәүләт
төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең
2018 елның 17 сентябрендәге 84
номерлы боерыгы белән расланды

## Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Регламент төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте, Регламент) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар булып төзүче (төзеп бирүче оешма) яки техник заказчы тора.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе (алга таба – Инспекция) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Инспекциянең урнашкан урыны (почта адресы): 420111, Казан ш., Зур Кызыл ур., 15/9 й.

Инспекциянең эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе 8.30дан 17.30 сәгатькәчә, җомга 8.30дан 16.30 сәгатькәчә, төшке аш 12.00дән 12.45 сәгатькәчә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, Инспекциянең эш сәгатьләрендә.

Җәмәгать транспортында «КАИ» яки «Ирек мәйданы» тукталышына кадәр барырга:

- № 10а, 22, 28, 28а, 30, 35, 54, 63,89, 91, 98 автобуслар;
- № 2, 3, 5, 7 троллейбуслар.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклаучы документ белән.

1.3.2. Белешмәләр алу өчен телефоннар:

237-91-87, 237-87-22 – Зур Кызыл ур., 15/9 й.

1.3.3. Инспекциянең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://gsn.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматны алырга мөмкин:

1) Инспекция биналарында урнашкан, дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге визуаль һәм текстлы мәгълүматтан торган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларына урнаштырыла торган мәгълүмат дәүләт хезмәте турында

бу Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» челтәре ярдәмендә:

Инспекциянең рәсми сайтында (http://gsn.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://www.uslugi.tatarstan.ru);

Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru);

3) Инспекциягә телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефоннан);

4) Инспекциягә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итеп.

1.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча кирәкле барлык мәгълүмат Инспекция аппаратының төзелеп беткән объектларны кабул итү тәртибенә күзәтчелек һәм өлешле төзелеш өлкәсендә контрольлек бүлегендә әзерләнә һәм, гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Инспекция биналарындагы мәгълүмат стендларына урнаштырыла һәм, Инспекциянең рәсми сайтына урнаштыру өчен, җыелма анализ бүлегенә тапшырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләргә туры китереп башкарыла:

Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы (алга таба – РФ ШТК) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, № 1, 16 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге № 69-ФЗ федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1994, № 35, 3649 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге № 181-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы № 52-ФЗ федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1999, № 14, 1650 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы № 7-ФЗ федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 2, 133 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Техник яктан җайга салу турында» 2002 елның 27 декабрендәге № 184-ФЗ федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 52, 5140 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге № 257-ФЗ федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2007, № 46, 5553 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге № 123-ФЗ федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, № 30, 3579 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент» 2009 елның 30 декабрендәге № 384-ФЗ федераль закон (Россия

Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 1, 5 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге № 63-ФЗ федераль закон (алга таба – № 63-ФЗ федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 1, 5 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы № 601 Указы (алга таба – РФ Президентының № 601 Указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә дәүләт төзелеш күзәтчелеге турында» 2006 елның 1 февралендәге № 54 карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең № 54 карары, РФ Хөкүмәтенең № 54 карары белән расланган Нигезләмә) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 7, 774 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Аларны мәҗбүри рәвештә куллану нәтиҗәсендә, «Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент» федераль закон таләпләренең үтәлеше тәэмин ителә торган илкүләм стандартлар һәм кагыйдәләр җыелмалары (андый стандартлар һәм кагыйдәләр җыелмаларының өлешләре) исемлеген раслау турында» 2014 елның 26 декабрендәге № 1521 карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 2, 465 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең «Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда, капиталь төзекләндергәндә, башкару документларын тутырып баруның составына һәм тәртибенә таләпләрне һәм эшләрне, конструкцияләрне, инженер-техник тәэмин итү челтәрләре участокларын тикшерү актларына куелучы таләпләрне раслау һәм гамәлгә кертү турында» 2006 елның 26 декабрендәге № 1128 боерыгы (Башкарма хакимиятнең федераль органнары норматив актлары бюллетене, 2007, № 13, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкарганда, тикшерүләр уздыру һәм төзелгән, үзгәртеп корылган, төзекләндерелгән капиталь төзелеш объектларының техник регламентлар (нормалар һәм кагыйдәләр), башка норматив хокукый актлар һәм проект документларының Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең 2006 елның 26 декабрендәге № 1129 боерыгы белән расланган таләпләренә туры килүе турында бәяләмәләр бирү тәртибе (алга таба – Ростехнадзорның 26.12.2006 ел, № 1129 боерыгы белән расланган Тәртип) (Башкарма хакимиятнең федераль органнары норматив актлары бюллетене, 2007, № 15, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең «Дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкарганда, эшләрне формалаштыру һәм алып бару тәртибен раслау һәм гамәлгә кертү турында» 2006 елның 26 декабрендәге № 1130 боерыгы (Башкарма хакимиятнең федераль органнары норматив актлары

бюллетене, 2007, № 13, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең «Капиталь төзелеш объектларын төзегәндәге, үзгәртеп коргандагы, капиталь төзекләндергәндәге эшләрнең үтәлешен исәпкә алуның гомуми һәм (яки) махсус журналын тутырып бару тәртибен раслау һәм гамәлгә кертү турында» 2007 елның 12 гыйнварындагы № 7 боерыгы (Башкарма хакимиятнең федераль органнары норматив актлары бюллетене, 2007, № 14);

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турында» 2006 елның 28 ноябрендәге № ПУ-505 Указы («Республика Татарстан» газетасы, 2006, № 237-238, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 елның 12 ноябрендәге № 622 карары (алга таба – ТР МКның № 622 карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 43, 1707 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 02.11.2010, № 880 карары (алга таба – ТР МКның № 880 карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торучы һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында» 13.08.2011, № 675 карары (алга таба – ТР МКның № 675 карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, 2011, № 39, 1928 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең «Татарстан Республикасы территориясендә капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда, капиталь төзекләндергәндә башкарылган эшләргә һәм кулланылучы төзелеш материалларына экспертизалар, тикшерүләр, лаборатор һәм башка төрле сынаулар уздыруга чыгымнарны каплау өчен түләү күләмен исәпләү тәртибен һәм исәпләү коэффициентларын раслау турында» 18.12.2009, № 9-9/нпс карары (алга таба – ТР Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең № 9-9/нпс карары) («Республика Татарстан», 2010 елның 15 гыйнвары);

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе

тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару буенча дәүләт функциясе үтәлүнең Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 04.12.2013, № 94 боерыгы белән расланган административ регламенты (алга таба – Функция буенча административ регламент) (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы PRAVO.TATARSTAN.RU, 2013 елның 19 декабре, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.5. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр файдаланыла:

гариза бирүчеләр – дәүләт хезмәте алучылар яки аларның вәкаләтле вәкилләре: төзүчеләр яки техник заказчылар;

төзүче – үзенеке булган җир участогында яки җиргә хокуклы башка (дәүләт (муниципалитет) милкендәге капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен биргәндә, дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), дәүләтнең бюджеттан тыш фондларын идарә итүче органнар яки җирле үзидарә органнары, Россия Федерациясенең бюджет законнары билгеләгән очракларда, үзләренең дәүләт (муниципалитет) заказчысы вәкаләтләрен килешүләр нигезендә аңа тапшырган) затның җир участогында капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны, капиталь төзекләндерүне, җимерүне, шулай ук аларны төзү, үзгәртеп кору, капиталь төзекләндерү өчен инженерлык тикшеренүләрен башкаруны, проект документларын әзерләүне тәэмин итүче физик яки юридик зат. Төзүче үзенең шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар белән күздә тотылган функцияләрен техник заказчыга тапшырырга хокуклы;

техник заказчы – төзүче тарафыннан вәкаләт бирелгән һәм инженерлык тикшеренүләрен башкару турында, проект документларын әзерләү турында, капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору, капиталь төзекләндерү, җимерү турында төзүче исеменнән килешүләр төзи, эшләрнең әлеге төрләрен башкаруга биремнәр әзерли, инженерлык тикшеренүләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче, капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны, капиталь төзекләндерүне, җимерүне башкаручы затларга эшләрнең күрсәтелгән төрләрен башкару өчен кирәкле материаллар һәм документлар бирә, проект документларын раслый, капиталь төзелеш объектын файдалануга кертүгә рөхсәт алу өчен кирәкле документларны имзалый, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар белән күздә тотылган башка төрле функцияләрне (алга таба шулай ук – техник заказчы функцияләре) үти торган юридик зат. Техник заказчы функцияләре, РФ ШТКның 47 статьясы 2.1 өлеше, 48 статьясы 4.1 өлеше, 52 статьясы 2.1 һәм 2.2 өлешләре, 55.31 статьясы 5 һәм 6 өлешләре белән күздә тотылган очраклардан гайре, бары тик, тиңдәшле рәвештә, инженерлык тикшеренүләре, архитектура-төзелеш проектларын ясау, капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору, капиталь төзекләндерү, җимерү өлкәсендә үзкөйләнешле оешма әгъзасы тарафыннан гына башкарылырга мөмкин;

вазыйфаи зат – Инспекциянең территориаль органы хезмәткәре, Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) боерыгы белән билгеләп куела, тәгаен бер капиталь төзелеш объектында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген законнарга туры китереп башкару өчен җаваплы;

төркем җитәкчесе – Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) боерыгына

тәңгәл рәвештә, вазыйфаи затлар арасыннан билгеләнә торган, оештыру һәм координацияләү өчен җаваплы, шулай ук вазыйфаи затларның дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару буенча эшчәнлегенә җитәкчелек итүче зат;

Инспекция аппаратының кабул итү бүлеге – Инспекция аппаратының дәүләт хезмәте күрсәтү эшен башкаручы, төзелеп беткән объектларны кабул итү тәртибенә күзәтчелек һәм өлешле төзелеш өлкәсендә контрольлек бүлеге;

территориаль органның кабул итү бүлеге – Инспекциянең территориаль органының дәүләт хезмәте күрсәтү эшен башкаручы, төзелеп беткән объектларны кабул итү тәртибенә күзәтчелек бүлеге;

территориаль орган җитәкчесе – Инспекциянең Татарстан Республикасы шәһәрләрендә һәм районнарында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару буенча структур бүлекчәсе җитәкчесе;

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципалитет учреждениесе оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 2010 елның 27 июлендәге № 201-ФЗ федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне, шул исәптән электрон рәвештә, «бер тәрәзә» принцибы буенча оештыруга вәкаләт бирелгән оешма;

«бер тәрәзә» принцибы – шундый принцип: дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү гариза бирүче дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында тиешле рәсми мөрәҗәгать белән яки 2010 елның 27 июлендәге № 201-ФЗ федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгать белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң башкарыла, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар белән хезмәттәшлек күпфункцияле үзәк тарафыннан, норматив хокукый актларга һәм үзара хезмәттәшлек турында килешүгә туры китереп, гариза бирүченең катнашыннан башка эшләнә;

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыруның РФ Хөкүмәтенең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге № 1376 карары белән расланган кагыйдәләренең 34 нче пунктына туры китереп, Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яки авыл җирлегендә төзелгән, территориаль яктан аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – Инспекция тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның мәгълүмат керткәндә нигез булып торган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата).

Бу Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – Гариза) төшенчәсе дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне аңлата (№ 210-ФЗ Федераль законның 2 статьясы 1 пункты).

Гаризаның киңәш ителүче формасы бу Регламентка 3 нче кушымтада

китерелгән.

2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпләрнең эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы | Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү | РФ Хөкүмәтенең № 54 карары белән расланган Нигезләмәнең 16 пункты |
| 2.2. Башкарма хакимиятнең дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче органы атамасы | Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе | ТР МКның № 622 карары |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында Бәяләмә (алга таба – ярашлылык турында бәяләмә) (1 нче кушымта) бирү;<br>ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар (2 нче кушымта) | РФ Хөкүмәтенең № 54 карары белән расланган Нигезләмәнең 19 пункты;<br>Ростехнадзорның 26.12.2006 ел, № 1129 боерыгы белән расланган Тәртипнең 29 пункты; |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт | Ярашлылык турында бәяләмә бирү хакында гариза теркәлгән көннән алып ун эш көне эчендә. | РФ Хөкүмәтенең № 54 карары белән расланган |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып; туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы | Дәүләт хезмәте күрсәтү срогын туктатып тору күздә тотылмаган. | Нигезләмәнең 19 пункты; Ростехнадзорның 26.12.2006 ел, № 1129 боерыгы белән расланган Тәртипнең 29 пункты; |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | 1. Ярашлылык турында бәяләмә бирү хакында гариза (3 нче кушымта).<br>2. Шәхесне таныклаучы документ.<br>3. Гариза бирүче исеменнән аның персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык бирүгә вәкаләтен күрсәтеп, вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкиле эш итсә).<br>Гариза бирүче гаризаны һәм аңа кушып бирелүче документларны түбәндәге ысулларның берсе белән кәгазьдә бирә (җибәрә) ала:<br>- шәхсән үзе (гариза бирүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат);<br>- почта аша.<br>Гариза бирүче гаризаны һәм документларны, квалификацияле көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәре аша һәм Татарстан Республикасы Дәүләт | РФ Хөкүмәтенең № 54 карары белән расланган Нигезләмәнең 19 пункты; Ростехнадзорның 26.12.2006 ел, № 1129 боерыгы белән расланган Тәртипнең 29 пункты; |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша да тапшырырга (җибәрергә) мөмкин. | |
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булып, мөрәҗәгать итүче тапшыруга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки оешмага аларны тапшыру тәртибе | Бу категориягә кертү мөмкин булган документлар тапшыру таләп ителми. | |
| 2.7. Норматив-хокукый актлар белән күздә тотылган очракларда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен аларның килештерүләре (дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла) таләп ителә торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре | Килештерү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләр юк. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аннан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуга нигезләр юк.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып торалар:<br>бу Регламентның 1.5 пункты нигезендә гариза бирүче булып тормаган затның мөрәҗәгать итүе;<br>төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерүнең башкарылган эшләрнең техник регламентлар (нормалар һәм кагыйдәләр), башка норматив хокукый актлар һәм проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалануга кагылышлы таләпләргә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлыгына кагылышлы таләпләренә туры килүнең бозылуы (алга таба – бозулар) язылган акты булу яки төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшергәндә ачыкланган бозылуларның бетерелүе турында актның булмавы;<br>капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда, капиталь төзеклəндергәндә башкарылган эшләргә һәм кулланылучы төзелеш | РФ Хөкүмәтенең № 54 карары белән расланган Нигезләмәнең 18-19 пунктлары;<br>Ростехнадзорның 26.12.2006 ел, № 1129 боерыгы белән расланган Тәртипнең 29 пункты;<br>Функция буенча административ регламент;<br>ТР МКның № 675 карары |

| | | |
|---|---|---|
| | материалларына экспертизалар, тикшерүләр, лаборатор һәм башка төрле сынауларның булмавы. | |
| 2.10. Дәүләт пошлинасы яки дәүләт хезмәте  күрсәткән өчен алына торган башка төрле түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр булып торалар: капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда, капиталь төзекләндергәндә башкарылган эшләргә һәм кулланылучы төзелеш материалларына экспертизалар, тикшерүләр, лаборатор һәм башка төрле сынаулар.<br>Төзелешне башкаручы зат башкарылган эшләргә һәм кулланылучы төзелеш материалларына экспертизалар, тикшерүләр, лаборатор һәм башка төрле сынаулар уздыруга чыгымнарны каплый.<br>Әлеге акчалар Федераль казначылыкның Татарстан Республикасындагы идарәсендәге бюджет керемнәре администраторының лицевой счетына языла.<br>Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда, капиталь төзекләндергәндә башкарылган эшләргә һәм кулланылучы төзелеш материалларына экспертизалар, тикшерүләр, лаборатор һәм башка төрле сынаулар уздыруга | ТР МКның  № 675 карары;<br>ТР Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең № 9-9/нпс карары; Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турында ТР МКның  № 622 карары белән расланган нигезләмәнең 4.1 пункты 4.1.5 пунктчасы |

| | | |
|---|---|---|
| | чыгымнарны каплау өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе ТР Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең № 9-9/нпс карары белән расланган. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә һәм андый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда, чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | РФ Президентының № 601 Указының 1 пункты |
| 2.13. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатен, шул исәптән электрон рәвештә, теркәү срогы | Гариза һәм документлар кергән көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнне электрон рәвештә кергән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көн артыннан килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, гариза бирүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, шул исәптән, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнарына тәңгәл рәвештә, әлеге объектларның инвалидлар файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат урнаштыруга һәм | Дәүләт хезмәте күрсәтү һаваны кондиционер белән суыту системасы; янгынга каршы система; документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар белән җиһазландырылган бинада һәм бүлмәләрдә башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарга, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урыныннан инвалидларның тоткарлыксыз файдалана алуы (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм алар эчендә күчеп йөрү) тәэмин ителә: инвалидларның | |

| | | |
|---|---|---|
| рәсмиләштерүгә карата таләпләр | файдалана алуын тәэмин итү максатларында, Зур Кызыл ур., 15/9 йорт адресы буенча урнашкан бинада бинаның алгы ягындагы керү урыныннан сулдарак инвалидлар өчен персоналны чакыру төймәсе куелган. Әлеге чакыру төймәсенә басып сигнал бирелгәч, Инспекция персоналы аларны бина эченә күчереп куя. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең мөмкинлек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән аралашулары саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләре булып торалар:<br>1) документларны кабул итү, бирү алып барыла торган биналарның җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашуы;<br>2) кирәкле санда белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итеп алына торган бүлмәләрнең булуы;<br>3) мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>4) мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең бинадагы дәүләт хезмәте күрсәтү урыныннан тоткарлыксыз файдалана алуын (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм алар эчендә күчеп йөрү) тәэмин итү;<br>5) биналарның инвалидлар файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйләнмәгән, аларның хезмәт күрсәтүләрне башка затлар белән бертигез алуына комачаулаучы башка киртәләрне узуда | |

| | | |
|---|---|---|
| | инвалидларга ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып торалар:<br>1) документларны кабул итү һәм карап тикшерү сроклары үтәлү;<br>2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогы үтәлү;<br>3) документларны кабул иткәндә һәм гариза бирүчеләргә биргәндә, чиратларның булмавы;<br>4) дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрнең булмавы.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда, дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр үзара аралашуы күздә тотыла.<br>Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәк аша, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары аша күрсәтелми.<br>Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турындагы мәгълүматны Инспекциянең рәсми сайтыннан (http://gsn.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан алырга мөмкин. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультация Инспекциянең рәсми сайтындагы | № 63-ФЗ федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | интернет-кабул итү бүлмәсе аша электрон рәвештә алынырга мөмкин.<br>Гариза бирүче гаризаны һәм документларны, квалификацияле көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәре аша һәм Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша да тапшырырга (җибәрергә) мөмкин. | |

## 3. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, үтәүнең эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы

3.1.1. Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә (алга таба – ярашлылык турында бәяләмә) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

гариза бирүчегә консультация бирү, ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

ярашлылык турында бәяләмә әзерләү һәм бирү яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту;

тапшырылган документларны тикшерү;

техник хатаны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы Регламентка 4 нче кушымтада бирелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Гариза бирүче, дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Инспекциягә шәхсән үзе, телефоннан, электрон почта аша һәм (яки) хат белән мөрәҗәгать итә.

Инспекция аппаратының кабул итү бүлеге (территориаль органның кабул итү бүлеге) белгече гариза бирүчегә гариза бланкын бирә, зарурлык булганда, бланкны тутыруда ярдәм күрсәтә, консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм исемлеге эчтәлеге буенча.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: консультацияләр, дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм исемлеге эчтәлеге буенча искәртмәләр.

3.3. Ярашлылык турында бәяләмә яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карарны әзерләү һәм бирү.

3.3.1. Ярашлылык турында бәяләмә яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карарны бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә, түбәндәге административ гамәлләр кылына:

1) ярашлылык турында бәяләмә бирү хакында гаризаны теркәү;

2) гаризаны карап тикшерү;

3) ярашлылык турында бәяләмә яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карарны формалаштыру;

4) ярашлылык турында бәяләмә яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карарны бирү (җибәрү).

3.3.2. Ярашлылык турында бәяләмә бирү хакында гаризаны теркәү.

Административ гамәлнең башланып китүе өчен нигез булып, гариза бирүчедән шәхсән яки вәкаләтле заты аша Инспекциягә Ярашлылык турында бәяләмә бирү хакында гариза һәм бу Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән документлар керү тора.

3.3.2.1. Инспекциянең Инспекциягә керүче корреспонденцияне теркәү һәм «Татарстан Республикасы электрон хөкүмәте» электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасында документ әйләнешен алып бару өчен җаваплы вазыйфаи заты (алга таба – ЭДӘБВС администраторы):

ярашлылык турында бәяләмә бирү хакында гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасында (алга таба – электрон хөкүмәт) терки;

ярашлылык турында бәяләмә бирү хакында гаризаны Инспекция башлыгына карап тикшерүгә җибәрә.

Инспекция башлыгы, Инспекция боерыгы белән расланган Эш башкару буенча аңлатма нигезендә, ярашлылык турында бәяләмә бирү хакында гаризаны төркем җитәкчесенә яки, ул булмаганда, вазыйфаи затка җибәрә.

Тапшырылган документлар бу Регламентның 2.5 пункты таләпләренә туры килгән очракта, төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат) кабул ителгән гаризаны, № 210-ФЗ федераль закон нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать буларак карап тикшерә.

Бу пункт билгели торган процедура гариза кергән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: ярашлылык турында бәяләмә бирү хакында кабул ителгән, теркәлгән һәм электрон хөкүмәт буенча төркем җитәкчесенә (вазыйфаи затка) карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.3.2.2. Тапшырылган документлар бу Регламентның 2.5 пункты таләпләренә туры килмәгән очракта, төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат) гариза бирүчегә кабул ителгән гаризаның, № 210-ФЗ федераль закон нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать буларак карап тикшерелмәве турында мәгълүмат хаты җибәрә.

3.3.3. Гаризаны карап тикшерү.

3.3.3.1. Төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат) ярашлылык турында бәяләмә бирү хакында гаризаны карап тикшерә һәм, искәртмәләр (бу Регламентның 1.5 пункты нигезендә гариза бирүче булып тормаган затның мөрәҗәгать итүе; төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерүнең таләпләр бозылу хакында язылмаган акты булмау; төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшергәндә ачыкланган бозылуларның бетерелүе турында актның булмавы) булган очракта, төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат) ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар проектын әзерли, аны территориаль орган җитәкчесе белән килештерүне һәм Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) имзалавын тәэмин итә һәм аны, бу Регламентның 3.3.5 пункты күздә тоткан гамәлләрне кылу өчен, Инспекция аппаратының кабул итү бүлегенә җибәрә.

Төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат) ярашлылык турында бәяләмә бирү хакында гаризаны карап тикшерә һәм, искәртмәләр булмаган очракта, төбәк

дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкарганда формалаштырылган эшне (алга таба – формалаштырылган эш) территориаль органның кабул итү бүлегенә яки, ул булмаганда, территориаль орган җитәкчесенә тапшыра.

Бу пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан алып бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: территориаль органның кабул итү бүлегенә (территориаль орган җитәкчесенә) җибәрелгән формалаштырылган эш яки Инспекция аппаратының кабул итү бүлегенә җибәрелгән ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар проекты.

3.3.3.2. Формалаштырылган эшне алгач, территориаль органның кабул итү бүлеге (территориаль орган җитәкчесе) аны составы һәм комплектлыгы ягыннан тикшерә.

Формалаштырылган эшне тикшерү барышында ачыкланган искәртмәләр булганда, территориаль органның кабул итү бүлеге (территориаль орган җитәкчесе) төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат) белән бергәләп аларны бетерүне тәэмин итә.

Искәртмәләр булмаган очракта яки аларны бетергәннән соң, территориаль органның кабул итү бүлеге (территориаль орган җитәкчесе) формалаштырылган эшне Инспекция аппаратының кабул итү бүлегенә тикшерүгә җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан алып ике эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Инспекция аппаратының кабул итү бүлегенә җибәрелгән формалаштырылган эш.

3.3.3.3. Инспекция аппаратының кабул итү бүлеге, формалаштырылган эшне алганнан соң, аның закон таләпләренә туры килүен, шул исәптән вазыйфаи затларның, дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкарганда, шәһәр төзелеше законнары, Функция буенча административ регламент таләпләрен үтәвен дә тикшерә.

Төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерү үткәргәндә, вазыйфаи затларның шәһәр төзелеше законнарын үтәвен тикшерү максатларында, Инспекция аппаратының кабул итү бүлеге, зарурлык булганда, капиталь төзелеш объектына үзе бара.

Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча, Инспекция аппаратының кабул итү бүлеге, ачыкланган бозуларны яки бозуларның булмавын күрсәтеп, хисап әзерли һәм аны Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) җибәрә. Әлеге хисап нигезендә, ярашлылык турында бәяләмә бирү яисә ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар кабул ителә.

Бу пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан алып ике эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: ярашлылык турында бәяләмә бирү яисә ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында кабул ителгән карар.

3.3.4. Ярашлылык турында бәяләмә яисә ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тартуны формалаштыру.

3.3.4.1. Ярашлылык турында бәяләмә бирү турында карар кабул ителгән очракта, территориаль органның кабул итү бүлеге яисә, ул булмаганда, төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат) ярашлылык турында бәяләмә бланкын бирүгә

гаризаның территориаль орган җитәкчесе тарафыннан, Инспекция аппаратының кабул итү бүлеге башлыгы һәм Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан имзалануын тәэмин итә.

Территориаль органның боерык белән вәкаләт бирелгән хезмәткәрләре финанс-икътисад контроле бүлегеннән ярашлылык турында бәяләмә бланкын алалар һәм аны, рәсмиләштерү өчен, территориаль органның кабул итү бүлегенә яисә, ул булмаганда, төркем җитәкчесенә (вазыйфаи затка) тапшыралар.

Бу пункт билгели торган процедура ярашлылык турында бәяләмә бирү турында карар яисә ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән алып бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: территориаль органның кабул итү бүлегенә яисә төркем җитәкчесенә (вазыйфаи затка) тапшырылган ярашлылык турында бәяләмә бланкы.

3.3.4.2. Территориаль органның кабул итү бүлеге төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат) белән бергәләп:

ярашлылык турында бәяләмә проектын һәм ярашлылык турында бәяләмә раслау турында күрсәтмә (бу Регламентка 5 нче кушымта) әзерли;

ярашлылык турында бәяләмә раслау турында күрсәтмәне территориаль орган җитәкчесе, Инспекциянең Хокук идарәсе башлыгы, Инспекция аппаратының кабул итү бүлеге башлыгы белән килештерә;

ярашлылык турында бәяләмә бланкын тутыра;

ярашлылык турында бәяләмәнең һәм ярашлылык турында бәяләмә раслау турында күрсәтмәнең төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерү үткәрүдә катнашкан барлык җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан, территориаль орган җитәкчесе тарафыннан, Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан имзалануын һәм аларның Инспекция аппаратының кабул итү бүлегенә тапшырылуын тәэмин итә.

Бу пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан алып бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Инспекция аппаратының кабул итү бүлегенә тапшырылган ярашлылык турында бәяләмә, ярашлылык турында бәяләмә раслау турында әмер.

3.3.4.3. Ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, территориаль орган җитәкчесе бу карарны территориаль органның кабул итү бүлегенә яки төркем җитәкчесенә (вазыйфаи затка) тапшыра.

Территориаль органның кабул итү бүлеге төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат) белән бергәләп, ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар проектын әзерли, аны территориаль орган җитәкчесе, Инспекциянең Хокук идарәсе башлыгы, Инспекция аппаратының кабул итү бүлеге башлыгы белән килештерә, аның Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан имзалануын тәэмин итә һәм Инспекция аппаратының кабул итү бүлегенә тапшыра.

Бу пункт билгели торган процедура бу Регламентның 3.3.3.3 пункты белән күздә тотылган процедура тәмамланган моменттан алып бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту

хакында Инспекция аппаратының кабул итү бүлегенә тапшырылган карар.

3.3.5. Ярашлылык турында бәяләмә яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту хакында карарны бирү (җибәрү).

3.3.5.1. Инспекция аппаратының кабул итү бүлеге:

ярашлылык турында бәяләмә раслау турында күрсәтмәне яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту хакында карарны терки;

ярашлылык турында бәяләмә бланкына Инспекциянең тугралы мөһере һәм клишесы эзләрен төшерүне тәэмин итә;

элемтәгә керүнең гаризада күрсәтелгән ысулы белән, гариза бирүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә;

гариза бирүченең (аның вәкиленең) кулына ярашлылык турында бәяләмә яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту хакында карарны бирә, бу вакытта гариза бирүченең (аның вәкиленең) шәхесен ачыклый, шул исәптән шәхесен таныклаучы документын тикшерә; аның гариза бирүче исеменнән эш итүгә вәкаләтләрен (ышанычнамәне) тикшерә.

Ярашлылык турында бәяләмәнең яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту хакында карарның икенче нөсхәсе Инспекция аппаратының кабул итү бүлегендә кала;

гариза бирүче (гариза бирүченең вәкиле) килмәгән очракта, ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту хакында карарны (ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту хакында карар карар кабул ителгән очракта) яки дәүләт хезмәте күрсәтү турында хатны (ярашлылык турында бәяләмә бирү хакында карар карар кабул ителгән очракта) почта белән җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедура гариза бирүче (гариза бирүченең вәкиле) килгән көнне яки, гариза бирүче (гариза бирүченең вәкиле) килмәгән очракта, моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан алып бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (гариза бирүченең вәкиленә) ярашлылык турында бәяләмә яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карарны бирү, яисә ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту хакында карарны (ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту хакында карар карар кабул ителгән очракта) яки дәүләт хезмәте күрсәтү турында хатны (ярашлылык турында бәяләмә бирү хакында карар карар кабул ителгән очракта) почта белән җибәрү.

3.4. Гариза бирүчеләргә дәүләт хезмәтен КФҮдә, ерактагы эш урыны аша күрсәтү.

Дәүләт хезмәте (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирү дә) күпфункцияле үзәктә, КФҮнең ерактагы эш урыннары аша күрсәтелми.

3.5. Техник хатаны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

Ярашлылык турында бәяләмәдә яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карарда техник хата (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата) табылган очракта, гариза бирүче Инспекциягә тапшыра:

техник хатаны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза (бу Регламентка 6 нчы кушымта);

техник хаталы (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хаталы) ярашлылык турында бәяләмә яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карарны;

юридик көчкә ия булып, техник хата (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата) барлыгын раслаучы документлар.

Ярашлылык турында бәяләмәдә яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карарда күрсәтелгән мәгълүматлардагы техник хатаны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза гариза бирүче тарафыннан шәхсән яисә вәкаләтле вәкиле аша кәгазьдә яки гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә бирелә.

Документлар белән тәэмин итү һәм контроль бүлеге техник хатаны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гаризаны кабул итә, кушып бирелгән документлар белән гаризаны терки.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза кергән моменттан алып бер көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

Территориаль органның кабул итү бүлеге яисә, ул булмаганда, төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат) документларны карап тикшерә һәм, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документларга төзәтмәләр кертү максатында, бу Регламентның 3.3.4 пунктында күздә тотылган процедураларны башкара һәм үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны Инспекция аппаратының кабул итү бүлегенә җибәрә.

Инспекция аппаратының кабул итү бүлеге, документның техник хаталы (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хаталы) төп нөсхәсен гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) алып, үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән, кул куйдырып тапшыра яисә гариза бирүче (гариза бирүченең вәкиле) адресына дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында почта белән хат җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедура техник хата (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата) табылганнан соң яисә җибәрелгән техник хата (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата) турында гариза бирүчедән (гариза бирүченең вәкиленнән) гариза алынганнан соң өч эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (гариза бирүченең вәкиленә) ярашлылык турында бәяләмә яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карарны бирү яки дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында почта белән хат җибәрү.

Ярашлылык турында бәяләмәә яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карарга орган һәм (яки) вазыйфаи зат гаебе белән җибәрелгән хаталарны төзәтүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертү очрагында гариза бирүчедән түләү алынмый.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына контрольлек үз эченә тикшерүләр үткәрүне, мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү, карарлар кабул итү һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләргә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлүенә контрольлек формалары булып, тикшерүләр үткәрү тора:

- эш башкаруны алып баруны, шул исәптән документларны кабул итү сроклары һәм тәртибе үтәлүне;
- документларны карау нәтиҗәләренең законнар (бу Регламент) таләпләренә туры килүен;
- дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе үтәлүне.

Тикшерүләр уздыруның ешлыгы даими характерда була.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар билгеләгән гамәлләрнең эзлеклелеген саклауга агымдагы контрольлек Инспекция аппаратының кабул итү бүлеге һәм Инспекция башлыгының шуңа җаваплы урынбасары тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольлекне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге Инспекциянең структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсе буенча, гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар, Россия Федерациясе законнарына туры китереп, җаваплылыкка тартыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү Инспекция башлыгы тарафыннан башкарыла.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар тарафыннан контрольлек итү Инспекция эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында гаризаларны (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә башкарыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, шулай ук вазыйфаи затларның яисә дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар судка кадәр тәртиптә шикаять белдерүгә хокуклы:

дәүләт граждан хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата – Инспекция башлыгына.

Инспекция башлыгының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.

5.2. Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылу;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән күздә тотылмаган документлар таләп итү;

2018 елның 18 октябреннән бу пунктның 3 нче пунктчасы түбәндәге редакциядә бәян ителә:

3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, гариза бирүчедән аларны тапшыру яки башкару Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән күздә тотылмаган документлар яисә мәгълүмат тапшыруны яки гамәлләр кылуны таләп итү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, аларны тапшыру Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән күздә тотылган документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тарту;

5) әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән күздә тотылмаган түләү таләп итү;

7) Инспекциянең, Инспекциянең вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуы;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирүнең срогы яки тәртибе бозылу;

9) әгәр туктатып торуның нигезләре федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән күздә тотылмаса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

2018 елның 18 октябреннән бу пункт түбәндәге эчтәлектәге яңа 10 нчы пунктча белән тулыландырыла:

10) № 210-ФЗ федераль законның 7 статьясы 1 өлешендәге 4 нче пункт белән күздә тотылган очраклардан гайре, дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүчедән аларның юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән, яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканда күрсәтелмәгән документлар яисә мәгълүмат таләп итү.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, дәүләт хезмәткәренең, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять язмача кәгазьдә яки электрон рәвештә бирелә.

Шикаять гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында бирелергә,

почта аша, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Инспекциянең рәсми сайтыннан (http://gsn.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru) файдаланып җибәрелергә мөмкин.

5.4. Шикаятьне карап тикшерү срогы – аны теркәгән көннән алып унбиш эш көне эчендә. Инспекциянең, Инспекциянең вазыйфаи затының гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан яисә җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына карата шикаять белдерү очрагында яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерү очрагында – аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның атамасы, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүченең – физик затның – фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар яисә гариза бирүченең – юридик затның – атамасы, урнашкан урыны, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәвен нигезләүче дәлилләр.

5.6. Гариза бирүче үзенең дәлилләрен раслаучы документлар (булганда) яки аларның күчермәләрен кушып бирергә мөмкин.

5.7. Шикаять аны тапшырган гариза бирүче яки гариза бирүченең вәкаләтле заты тарафыннан имзалана.

5.8. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, түләтү Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары белән күздә тотылмаган акчаны гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Бу пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көн артыннан килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон рәвештә, шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

2018 елның 18 октябреннән бу бүлек түбәндәге эчтәлектәге яңа $5.8^1$ һәм $5.8^2$ пунктчалары белән тулыландырыла:

5.8[1]. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә җибәрелә торган бу Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта дәүләт хезмәте күрсәткәндәге ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында, Инспекция тарафыннан кылынучы гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм гариза бирүчегә дәүләт хезмәте алу максатларында алга таба башкарырга кирәкле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8[2] . Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә җибәрелә торган бу Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау буенча вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат, булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

(Форма)

ТР ДТК Инспекциясе башлыгы әмере белән расланды

«___»_______ _____ ел.

№ ____________

Эш номеры _________________

Нөсхә №___

_____________________________________

(җитәкче яки аның вазыйфаларын башкаручы зат, яки үзенең вәкаләтләренә һәм вазыйфалар бүленешенә туры китереп, дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкаруга җаваплы зат)

# ТӨЗЕЛГӘН, ҮЗГӘРТЕП КОРЫЛГАН КАПИТАЛЬ ТӨЗЕЛЕШ ОБЪЕКТЫНЫҢ ПРОЕКТ ДОКУМЕНТЛАРЫ ТАЛӘПЛӘРЕНӘ, ШУЛ ИСӘПТӘН ЭНЕРГИЯНЕ НӘТИҖӘЛЕ ФАЙДАЛАНУ ТАЛӘПЛӘРЕНӘ ҺӘМ КАПИТАЛЬ ТӨЗЕЛЕШ ОБЪЕКТЫНЫҢ ФАЙДАЛАНЫЛУЧЫ ЭНЕРГЕТИКА РЕСУРСЛАРЫН ИСӘПКӘ АЛУ ПРИБОРЛАРЫ БЕЛӘН ҖИҺАЗЛАНГАНЛЫК ТАЛӘПЛӘРЕНӘ ТУРЫ КИЛҮЕ ТУРЫНДА

## БӘЯЛӘМӘ

_____________________ «___»__________ 20___ ел.

(язу урыны)

Әлеге БӘЯЛӘМӘ бирелде:_____________________________________________________

(төзүченең яки техник заказчының атамасы,

_____________________________________________________________________________

дәүләт теркәве турында таныклыкның номеры һәм бирү көне, ОГРН, ИНН,

_____________________________________________________________________________

почта реквизитлары, телефон/факс – юридик затлар өчен;

_____________________________________________________________________________

фамилия, исем, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны, телефон/факс – физик затлар,

_____________________________________________________________________________

шәхси эшкуарлар өчен (дәүләт теркәве турында таныклыкның номеры һәм бирү көне))

һәм раслый: капиталь төзелеш объекты ____________________________________________

(проект документларына тәңгәл рәвештә,

______________________________________________________________________________
капиталь төзелеш объекты атамасы, кыскача проектлау сыйфатламалары, төзү, үзгәртеп кору этабы тасвирламасы
______________________________________________________________________________
(әгәр рөхсәт төзү, үзгәртеп кору этабына бирелсә))

түбәндәге адрес буенча урнашкан:_______________________________________________
(объектның почта яки төзелеш адресы)

______________________________________________________________________________

Капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга рөхсәт

______________________________________________________________________________
(номеры һәм бирү көне, кем тарафыннан бирелгән, гамәлдә булу срогы)

______________________________________________________________________________

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы таләпләренә тәңгәл рәвештә, проект документлары экспертизасының уңай бәяләмәсе___________________________________
(номеры һәм бирү көне, кем тарафыннан бирелгән)

______________________________________________________________________________

әгәр капиталь төзелеш объектының проект документлары дәүләт экологик экспертизасын узарга тиеш булса, проект документларына дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсе
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(номеры һәм бирү көне, кем тарафыннан бирелгән)

төзелешнең, үзгәртеп коруның, шул исәптән мәдәни мирас объектын саклап калу буенча конструктив һәм андый объектның ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгының башка сыйфатламаларына кагылучы эшләрнең башлануы ______________________________________
(эшләрнең башлану көне)

төзелешнең, үзгәртеп коруның, шул исәптән мәдәни мирас объектын саклап калу буенча конструктив һәм андый объектның ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгының башка сыйфатламаларына кагылучы эшләрнең тәмамлануы _____________________________________
(эшләрнең тәмамлану көне)

_____________________________________________________________ таләпләренә ТУРЫ КИЛӘ.
(проект документлары атамасы күрсәтелә)

Бу БӘЯЛӘМӘНЕ бирү өчен нигез булып торалар: _______________________________________

______________________________________________________________________________
(төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерү акты номеры, көне
______________________________________________________________________________
һәм үткәрелгән очракта, элегрәк бирелгән күрсәтмәне тикшерү актының номеры, көне)

______________________________ _______________ _____________________________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза)

Бәяләмәнең нөсхәсен алдым: _____________________________________________________
(вәкиллек турындагы документның реквизитларын күрсәтеп, төзүченең яки техник заказчының вәкиле тарафыннан тутырыла)

______________________________ _______________ _____________________________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза)

Искәрмә:
1) Бәяләмә дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының төзелеп (үзгәртеп корылып) беткән объектны тикшерү (тикшерүләр) үткәрүдә катнашкан җаваплы вазыйфаи затлары тарафыннан имзалана.

Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

(Форма)

Эш номеры _________________
Нөсхә №___

ТӨЗЕЛГӘН, ҮЗГӘРТЕП КОРЫЛГАН КАПИТАЛЬ ТӨЗЕЛЕШ ОБЪЕКТЫНЫҢ ПРОЕКТ ДОКУМЕНТЛАРЫ ТАЛӘПЛӘРЕНӘ, ШУЛ ИСӘПТӘН ЭНЕРГИЯНЕ НӘТИҖӘЛЕ ФАЙДАЛАНУ ТАЛӘПЛӘРЕНӘ ҺӘМ КАПИТАЛЬ ТӨЗЕЛЕШ ОБЪЕКТЫНЫҢ ФАЙДАЛАНЫЛУЧЫ ЭНЕРГЕТИКА РЕСУРСЛАРЫН ИСӘПКӘ АЛУ ПРИБОРЛАРЫ БЕЛӘН ҖИҺАЗЛАНГАНЛЫК ТАЛӘПЛӘРЕНӘ ТУРЫ КИЛҮЕ ТУРЫНДА БӘЯЛӘМӘ БИРҮДӘН

БАШ ТАРТУ ТУРЫНДА КАРАР

______________________ «___»__________ 20___ ел.
(язу урыны)

Бу КАРАР бирелде _______________________________________________________________
(төзүче яки техник заказчының атамасы (техник заказчы булганда),

_____________________________________________________________________________
дәүләт теркәве турында таныклыкның номеры һәм бирү көне, ОГРН, ИНН, почта реквизитлары,

_____________________________________________________________________________
телефон/факс – юридик затлар өчен; төзүченең яки техник заказчының фамилиясе, исеме, атасының исеме,

_____________________________________________________________________________
паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны, телефон/факс – физик затлар,

_____________________________________________________________________________
шәхси эшкуарлар өчен (дәүләт теркәве турында таныклыкның номеры һәм бирү көне))

төзелгән, үзгәртеп корылган, мәдәни мирас объектын саклап калу буенча конструктив һәм андый объектның ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгының башка сыйфатламаларына кагылучы эшләр тәмамланган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында БӘЯЛӘМӘ бирүдән баш тарту турында

капиталь төзелеш объекты ______________________________________________
(проект документларына тәңгәл рәвештә,

________________________________________________________________________
капиталь төзелеш объекты атамасы, кыскача проектлау сыйфатламалары, төзү, үзгәртеп кору этабы тасвирламасы

________________________________________________________________________
(әгәр рөхсәт төзү, үзгәртеп кору этабына бирелсә))

түбәндәге адрес буенча урнашкан: ________________________________________
(капиталь төзелеш объектының почта яки төзелеш адресы)

_______________________________________________________________________,

Капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт __________________________________
(номеры һәм бирү көне, кем тарафыннан бирелгән, гамәлдә булу срогы)

_______________________________________________________________________,

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы таләпләренә тәңгәл рәвештә, проект документлары экспертизасының уңай бәяләмәсе__________________________
(номеры һәм бирү көне, кем тарафыннан бирелгән)

_______________________________________________________________________,

әгәр капиталь төзелеш объектының проект документлары дәүләт экологик экспертизасын узарга тиеш булса, проект документларына дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсе

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________
(номеры һәм бирү көне, кем тарафыннан бирелгән)

төзелешнең, үзгәртеп коруның, шул исәптән мәдәни мирас объектын саклап калу буенча конструктив һәм андый объектның ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгының башка сыйфатламаларына кагылучы эшләрнең башлануы ______________________________
(эшләрнең башлану көне)

төзелешнең, үзгәртеп коруның, шул исәптән мәдәни мирас объектын саклап калу буенча конструктив һәм андый объектның ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгының башка сыйфатламаларына кагылучы эшләрнең тәмамлануы ____________________________
(эшләрнең тәмамлану көне)

Бу КАРАР төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерү нәтиҗәләре нигезендә кабул ителде ___________________________________________________________
(төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын һ.б. тикшерү акты номеры, көне)

_______________________________________________________________________,

тикшерү ачыклады ______________________________________________________
(таләпләре бозылган һәм төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерү үткәрү көненә бозулар төзәтелмәгән проект документларының атамасы, статьялар, пунктлары күрсәтелә)

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

____________________ ______________________ ________________________

_____________ ___________________________________________________________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза)

Бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы карар нөсхәсен алдым:_____________________

________________________________________________________________________

(вәкиллек турындагы документның реквизитларын күрсәтеп, төзүченең яки техник заказчының вәкиле тарафыннан тутырыла)

______________________________ ______________ ____________________________

(вазыйфа) (имза) (тулы имза)

Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

(Форма)

Кемгә:___________________________________

_________________________________________

Кемнән: _________________________________

_________________________________________

Оешманың һәм юридик затның оештырылу-хокукый формасының тулы атамасы, кем йөзендә:

_________________________________________

(җитәкченең яки вәкаләтле башка затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Элемтәгә керү өчен мәгълүмат:

Тел. _____________________________________

Электрон почта (гариза бирүченең вәкиленеке):

___________________________________________

Гариза бирүченең (гариза бирүченең вәкиленең) почта адресы:

_________________________________________

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза

Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалануга кагылышлы таләпләргә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлыгына кагылышлы таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирүне үтенәм

___________________________________________________________________________

төзүгә (үзгәртеп коруга) рөхсәт нигезендә, капиталь төзелеш объекты атамасы, адресы

Кушымта (гариза бирүче күрсәтә торган барлык документларны атарга һәм һәр документтагы битләр санын күрсәтергә):

_______________________________________________________________________________

Дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның шулар нигезендә карарлар кабул итүен дә кертеп, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системага салу, туплау, саклау, төгәллек кертү (яңарту, үзгәртү), файдалану, тарату (шул исәптән тапшыру), иясезләндерү, бикләү, юкка чыгаруга, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысасында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләргә) (шул исәптән автоматлаштырылган режимда) ризалыгымны (мәнфәгатьләрне вәкил буларак яклаган очракта, мин аның исеменнән эш иткән затның ризалыгын) раслыйм.

Шушының белән раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә (мәнфәгатьләрне вәкил буларак яклаган очракта, мин аның исеменнән эш иткән затныкына) кагылышлы, шулай ук түбәндәрәк минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага кушып бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары билгеләгән таләпләргә туры килә; гариза тапшыру моментына ул документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматлардан торалар.

Бу ризалык мәгълүматларны эшкәртүнең чик срокларын билгеләми.

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкны кире алу тәртибе миңа таныш.

Имза _____________ __________________________________
(тулы имза)

Дата ________________

Гариза кабул ителде: гаризаны кабул итүгә вәкаләтле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме


Имза _____________ __________________________________
(тулы имза)

Дата ________________

Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

# Блок-схема

| Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен оештыру | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Инспекциянең Инспекциягә керүче корреспонденцияне теркәү һәм «Татарстан Республикасы электрон хөкүмәте» Электрон документ әйләнешенең ведомствоара бердәм системасында документ әйләнешен алып бару өчен җаваплы вазыйфаи заты | Инспекция башлыгы, Инспекция башлыгы урынбасары, территориаль орган җитәкчесе, территориаль органның кабул итү бүлеге башлыгы, төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат) | Төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат) | Инспекциянең территориаль органының капиталь төзелеш объектларын төзүгә, үзгәртеп коруга күзәтчелек бүлеге (территориаль орган җитәкчесе) | Инспекция аппаратының төзелеп беткән объектларны кабул итү тәртибенә күзәтчелек бүлеге | Төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат), Инспекциянең территориаль органының капиталь төзелеш объектларын төзүгә, үзгәртеп коруга күзәтчелек бүлеге, территориаль орган җитәкчесе, Инспекция аппаратының кабул итү бүлеге, Инспекция башлыгы урынбасары, гариза бирүче |



Гариза бирүче булып тормаган затның мөрәҗәгать итүе; төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерүнең таләпләр бозылу язылмаган акты булмау; төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшергәндә ачыкланган бозылуларның бетерелүе турында актның булмавы очракларында, ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар проекты әзерләнә һәм Инспекция аппаратының кабул итү бүлегенә җибәрелә

Искәртмәләр булмаганда (гариза бирүче булып торган затның мөрәҗәгать итүе; төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерүнең таләпләр бозылу язылмаган акты булу яки төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшергәндә ачыкланган бозылуларның бетерелүе турында акт булу), формалаштырылган эш территориаль органның кабул итү бүлегенә яки территориаль орган җитәкчесенә тапшырыла.

Формалаштырылган эш Инспекция аппаратының кабул итү бүлегенә тикшерүгә җибәрелә (моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан алып ике эш көне эчендә)

Ярашлылык турында бәяләмә бирү яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен, Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) хисап әзерләү (моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан алып ике эш көне эчендә)

Техник хатаны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү

Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

(Форма)

КҮРСӘТМӘ

_____________ Казан ш. № _________

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә дәүләт төзелеш күзәтчелеге турында» 2006 елның 1 февралендәге № 54 карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 елның 12 ноябрендәге № 622 карарына, Ростехнадзорның 26.12.2006 ел, № 1129 боерыгы таләпләренә, Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Инспекциянең 2018 елның 17 сентябрендәге № 84 боерыгы белән расланган административ регламентына таянып һәм төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерүнең ______________ № ________________ акты нигезендә,

________________________________ адресы буенча урнашкан төзелеп беткән объектның _________________________ проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүен РАСЛЫЙМ.

Башлык урынбасары ____________________

Искәрмә: арткы якта әмер Инспекция аппаратының кабул итү бүлеге башлыгы, Хокук идарәсе башлыгы, территориаль орган җитәкчесе тарафыннан имзалана.

Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башлыгына
кемнән___________________________________

Техник хатаны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә __________________________________________________
(хезмәт күрсәтүнең атамасы)
җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.
Язылган:_____________________________________________________________________
Дөрес мәгълүматлар: __________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документка тиешле үзгәрешләр кертүне үтенәм.

Түбәндәге документларны кушып бирәм:

1.
2.
3.

Техник хатаны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гаризаны кире кагу хакында карар кабул ителгән очракта, андый карарны җибәрүне үтенәм:

E-mail: _______________ адресына электрон документ җибәрү ярдәмендә;

расланган күчермә рәвешендә почта аша кәгазьдә түбәндәге адреска: ___________________________________________________________________.

Дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның шулар нигезендә карарлар кабул итүен дә кертеп, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системага салу, туплау, саклау, төгәллек кертү (яңарту, үзгәртү), файдалану, тарату (шул исәптән тапшыру), иясезләндерү, бикләү, юкка чыгаруга, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысасында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләргә) (шул исәптән автоматлаштырылган режимда) ризалыгымны (мәнфәгатьләрне вәкил буларак яклаган очракта, мин аның исеменнән эш иткән затның ризалыгын) раслыйм.

Шушының белән раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә (мәнфәгатьләрне вәкил буларак яклаган очракта, мин аның исеменнән эш иткән затныкына) кагылышлы, шулай ук түбәндәрәк минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага кушып бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары билгеләгән таләпләргә туры килә; гариза тапшыру моментына ул документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматлардан торалар.

______________ ________________ ( ________________)
(дата) (имза) (Ф.И.О.)

Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә)

## Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары

### Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башлыгы | (843) 237-91-87 | Vasiliy.Kudryashov@tatar.ru |
| Башлыкның беренче урынбасары | (843) 237-91-87 | Ilfart.Safiullin@tatar.ru |
| Инспекция башлыгы урынбасары | (843) 518-48-99 | Rafail.Gayanov@tatar.ru |
| Инспекция башлыгы урынбасары | (843) 237-91-87 | Linar.Fatyhov@tatar.ru |

### Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юллар хуҗалыгы идарәсе башлыгы | (843) 264-77-16 | Ildar.Sibgatullin@tatar.ru |
| Юл һәм төзелеш комплексларында инвестиция программаларын тормышка ашыру бүлеге башлыгы | (843) 264-77-24 | Yuriy.Azin@tatar.ru |